РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » февраль 2018 ел Буа шәһәре № 40/ИК-п

Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы
Татарстан Республикасы Законын гамәлгә
ашыру комиссиясе турында

Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Законын ( ТР Законы 28.07.2004 ел N 44-ЗРТ, 03.12.2009ел N 54-ЗРТ, 03.03.2012 ел N 16-ЗРТ редакциясендә), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2013 елның 25 октябрендәге 794 нче номерлы карары белән расланган, “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” Дәүләт программасын, гамәлгә ашыру максатыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Буа муницапаль районы комиссиясен төзергә.
2. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Буа муницапаль районы комиссиясе турында нигезләмәне 1нче Кушымта нигезендә расларга .
3. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Буа муницапаль районы комиссия составын 2нче Кушымта нигезендә расларга .
4. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Буа муницапаль районы комиссиянең эш планын 3нче Кушымта нигезендә расларга .
5. Буа муниципаль райоы Башкарма комитетының 2014 елның 28 гыйнварындагы 24-п нче номерлы «Телләр буенча Буа районы комиссиясен булдыру» дигән карары үз көчен югалткан дип санарга.
6. Әлеге карарның үтәлүен тикшерүне, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н.Садретдиновага йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Камәртдинов

Кушымта №1
Буа муниципаль районы Башкарма
комитетының карарына
№ 40/ЫК-п от 08.02.2018

**Татарстан Республикасы телләре турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру буенча Буа муниципаль районы комиссиясе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы телләре турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру буенча Буа муниципаль районы комиссиясе  (алга таба – Комиссия) даими гамәлдәге орган булып тора һәм ул “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр” диеп исемләнгән Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар планы турында бердәм якын килүне төзү һәм үтәү турындагы җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр эшчәнлеген координацияләүне, оешмалар формалаштыруны гамәлгә ашыра

1.2 Комиссия үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Президенты Указларына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, җирле үзидарә органнары карарларына, боерыкларына һәм шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Комиссия Буа муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә һәм аның составында рәис (Башкарма комитет җитәкчесе), ике рәис урынбасарлары, секретарь һәм комиссия әгъзалары бар. Хәзерге эшне һәм комиссия карарларының эшләнүен тикшерүне комиссия секретаре гамәлгә ашырырга тиеш.

## 2. Максатлар һәм бурычлар

2.1 Комиссиянең төп бурычлары:

“Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр” дип исемләнгән Татарстан Республикасы Законы эшләнүен күзәтү;

Буа муниципаль районында “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр” диеп исемләнгән Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү

мәктәпкәчә белем учреждениеләрендә һәм уку йортларында ана телендә укыту, тәрбияләү буенча муниципаль районның тиешле оешмаларына һәм учреждениеләрендә кирәкле шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен өйрәнү буенча төрле өлкәләрдә лексик минимум күләмен үзләштерү; муниципаль районның оешмаларына һәм учреждениеләренә чаралар оештыруда гамәли һәм методик ярдәм итү, түгәрәкләр һәм кыска сроклы курслар оештыру.

географик атамалар һәм язмаларның исемнәрен үзгәртү, географик һәм топономик исемнәре каталогын булдыру, җыю эшләрен оештыру һәм ачыклау. Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башка телләр»Законына туры китереп топонимнарның язылышы элмә такталарны, язу юл күрсәткечләренең этикет, ярлыкларын һәм күрсәтмәләрне яраклаштыру.

2.2. Комиссия йөкләтелгән бурычларны хәл итү максатыннан:

республика һәм җирле тәҗрибәләрне өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерүне оештыра, беренче чиратта чишү кирәк булган сорауларны билгели;

муниципаль район җирле үзидәрә органнарына оешмалардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән кергән тәкъдимнәрне карый;

үз эше буенча барлык сорауларны җирле үзидәрә органнары белән хәл итә;

Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башка телләр» Законын тормышка ашырганда үз компетенциясе эчендә җирле үзидарә органнарына тәкъдим белән чыга.

## 3.Комиссиясенең эш тәртибе

3.1. Комиссиянең хокуклары:

комиссиянең компетенциясендә җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук предприятиеләрдән, учреждение һәм оешмалардан эшчәнлекләре буенча материаллар алу;

комиссияснең компетенциясендә комиссия утырышларында хәбәрләр һәм тәкъдимнәр тыңлау, компетенциягә кагылышлы сораулар буенча муниципаль районның оешмалары һәм учреждениеләре , предприятиеләре җирле үзидәрә органнары өчен мәҗбүри үтәү буенча карарлар кабул итү;

комиссиянең эшчәнлеге буенча төрле юнәлештәге эксперт һәм эшче комиссияләр оештыру.

3.2 МКУ “Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» комиссиянең
техник – оештыру эшчәнлеген тәэмин итә.

3.3 Комиссия утырышлары эш планы нигезендә кварталга бер тапкыр уздырыла, аның рәисе тарафыннан кабул ителә һәм расланa;
Утырышта әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашса, аны узган дип санарга.

Кушымта №2
Буа муниципаль районы Башкарма
комитетының карарына
№ 40/ИК-п 08.02.2018

**Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Буа муниципаль районы Башкарма комитеты комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе** - Буа муниципаль Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Камәртдинов;

**Комиссия рәисе урынбасары** - Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Садретдинова;

**Комиссия рәисе урынбасары** – Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары - МКУ «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» башлыгы И.Ф. Ханбиков;

**Комиссия сәркатибе** – Әхмәтҗанова Л.М. - МБУ «Буа туган якны өйрәнү музее» директоры.

**Комиссия әгъзалары:**

Гыймранов Р.Җ. - МКУ «Буа муниципаль районы мәдәният идарәсе» житәкчесе;

Садыйков Л.М.- МКУ «Буа муниципаль районы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» җитәкчесе ;

Камалетдинов Г.А. - «Байрак» («Знамя», «Ялав») район газетасының баш мөхәррире;

Зиннәтуллин Л.Б. - МБГББУ "Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия" директоры;

Лукоянов Б.С. – МБГББУ "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят урта гомуми белем мәктәбе» директоры;

Терентьев Д.В. - МБГББУ "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Рунга урта гомуми белем мәктәбе» директоры;

Абидуллина Р.М. - Буа шәһәре МБМББУ «АБВГДейка» балалар бакчасы мөдире;

Айзетуллова Г.Х. - ТР язучылар берлеге әгъзасы;

Голубева А.А. - Буа муниципаль районы Башкарма комитетынын территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе;

Зайцева С.А. - Буа шәһәре башлыгы урынбасары ;
Хөснетдинова З.И. - районның ветераннар Советы рәисе;
Фәткуллина И.З. - МБУ “ТР Буа муниципаль районы җирлекара үзәк китапханә”се директоры.

Кушымта №3
Буа муниципаль районы Башкарма
комитетының карарына
№ 40/ЫК-п от 08.02.2018

**Буа муниципаль районы комиссиясенең Татарстан Республикасы телләре турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру буенча эш планы**

| № п/п | Чаралар исемлеге | Үтәлү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | Эшне “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр” дип исемләнгән Татарстан Республикасы Законы, 2014-2020 еллардагы Татарстан Республикасының дәүләт һәм башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү турындагы Дәүләт программасы белән килешеп эшләү. | Ел дәвамында | Барлык милек җитәкчеләре |
| 2. | Татарстан Республикасы дәүләт телләре эшчәнлеген дәвам итү:<br>– карарлар һәм күрсәтмәләрне әзерләгәндә һәм чыгарганда;<br>– киңәшмәләр үткәргәндә;<br>– гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул иткәндә һәм караганда | Ел дәвамында | Барлык милек җитәкчеләре |
| 3. | Буа муниципаль районының хезмәт күрсәтү һәм мәдәният өлкәсендә ТР ике дәүләт телен дә куллану | Ел дәвамында | Мәдәният һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендәге җитәкчеләр |
| 4. | Матбугат атрибутикасында ТР ике дәүләт телен дә куллануның күрсәткечләрен булдыру. | Ел дәвамында | Реклама агентлыгы, массакүләм мәгълүмат чаралары |
| 5. | ТР бюджет өлкәсе хезмәткәрләре арасында ике дәүләт телен белүчеләрнең мәгълүмат базасын алып баруын дәвам иту. | Ел дәвамында | Бюджет өлкәседәге оешма җитәкчеләре |

| №<br>п/п | Чаралар исемлеге | Үтәлү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 6. | Бюджет өлкәсендәге учреждениеләрнең һәм оешмаларның компьютер технологияләрендә ТР дәүләт телләренең функцияләштерүен тәэмин итәргә. | Ел дәвамында | Бюджет өлкәсендәге оешма җитәкчеләре |
| 7. | Республика, район, шәһәр күләмендә узган чараларны ТР да яшәүче башка халыкларның һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә үткәрергә ярдәм итәргә. | Ел дәвамында | Мәдәният идарәсе<br>Мәгариф идарәсе |
| 8. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм ТР да яшәүче башка халыкларның телләрен, өйрәнү һәм үстерү белән шөгыльләнүче балалар һәм яшьләрнең иҗатын үстерүне тәэмин итү өчен шартлар тудыру. | Ел дәвамында | Мәдәният идарәсе<br>Мәгариф идарәсе |
| 9. | Буа муниципаль районы халкының дәүләт теле буларак рус һәм татар телләрен түләүсез һәм ирекле рәвештә өйрәнүне оештыру, матди-техник шартлар булдыру. | Ел дәвамында | Мәгариф идарәсе |
| 10. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү өчен үз эшеңне барлык милек формасындагы оешма җитәкчеләре белән координацияләргә. | Ел дәвамында | Барлык милек җитәкчеләре |
| 11. | Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен. саклау, өйрәнү һәм үстерү Программасын тормышка ашыру нәтиҗәләре турында фикер алышу үткәрергә. | II, IV квартал | Телләр буенча комиссия |
| 12. | Телләр буенча Комиссия утырышларын үткәрергә: | Кварталга бер тапкыр | |
| 12.1. | 1. Буа муниципаль районы комиссиясенең 2017нче елда Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча эшләнгән эшләрнең нәтиҗәләре һәм 2018 елга бурычлары. 2018 елга Комиссиянең эш планын раслау.<br>2. Буа муниципаль районында 2018 елга. Татарстан | Февраль, 2018нче ел | Татарстан Республикасының телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру |

| №<br>п/п | Чаралар исемлеге | Үтәлү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| | Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча, үткәреләчәк чараларының План проектын карау<br>3. Буа муниципаль районында. Халыкара туган тел көнен оештыру һәм уздыру. | | буенча төзелгән Буа муниципаль районы комиссиясе |
| 12.2. | 1. Буа муниципаль районы территориясендә ТР дәүләт телләрендә урам һәм юл күрсәткечләрен рәсмиләштерү (Телләр турындагы Законны сәүдә объектларында һәм транспорт, мәгариф һәм мәдәният учреждениеләрендә үтәлеше предметына планлы рейд үткәрү буенча нәтиҗәләр).<br>2. 2018 нче елның 1 нче яртыеллыгына ТР яшәүче халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү Программасын тормышка ашыру буенча нәтиҗәләр. | Май,<br>2018 нче ел | Буа муниципаль районы Татарстан Республикасының телләр турында законнарны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы комиссиясе |
| 12.3. | 1. Буа муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкларның милли – мәдәни үзенчәлеген саклап калу,<br>2. ТР дәүләт һәм башка телләрендә мәдәни чаралар (Шәһәр көне, Республика Көне, халыклар бердәмлеге Көне) оештыру һәм үткәрү. | Август,<br>2018 нче ел | Буа муниципаль районы Татарстан Республикасының телләр турында законнарны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы комиссиясе |
| 12.4. | 1. 2018 елда ТР Буа муниципаль районында милли мәгариф Концепциясен тормышка ашыру барышы турында.<br>2. 2018 нче елның 2 нче яртыеллыгына ТР яшәүче халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү Программасын тормышка ашыру буенча нәтиҗәләр. | Ноябрь,<br>2018 нче ел | Буа муниципаль районы Татарстан Республикасының телләр турында законнарны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы комиссиясе |